СОВЕТ ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

02.02.2021 пос. Октябрьский 06-35

### Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә бердәм башкарма орган буларак катнашу яисә аларның коллегиаль органнары составына керү өчен рөхсәтен алу тәртибе турындагы Нигезләмәне юкка чыгару хакында

«Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019нчы елның 16нчы декабреннән 432-ФЗ Федераль закон нигезендә,

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керү өчен рөхсәтен алу тәртибе турындагы Октябрьский авыл җирлеге Советының 2017нче елның 27нче сентябрендәге 28-128 номерлы карары белән расланган Нигезләмәне гамәлдән чыгарырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Югары Ослан муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге Советының законлылык, хокук тәртибе һәм регламент буенча даими комиссиясенә әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту йөкләнә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы Ш. Р. Азизов